Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XVI-6**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 15 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 29 декабрендәге «Даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга акчалата бүләкләүләрне, Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» XXIII-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсе, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 29 декабрендәге «Даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга акчалата бүләкләүләрне, Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» XXIII-3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1 пунктның уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә ай саен компенсация түләүләрен билгеләү һәм исәпләү тәртибе 11 нче кушымта нигезендә;»;

1.2) 11 нче кушымтаны яңа редакциядә әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Карарның гамәлдә булуы 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Бу карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2012 елның 29
декабрендәге XXIII-3 номерлы
карарына кушымта “11
(Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль район
Советының 2017 елның 15
февралендәге XVI-6 номерлы карары
редакциясендә)

## Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә ай саен компенсация түләүләрен билгеләү һәм исәпләү ТӘРТИБЕ

### I.Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Тәртип нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә ай саен компенсация түләүләрен билгеләү һәм исәпләү тәртибен билгели

### II. Өстәмәне билгеләү тәртибе һәм шартлары

2.1. Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә ай саен түләнә торган компенсация түләү вазыйфаларның югары, төп, әйдәүче һәм өлкән төркемнәренең муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча биләгән эш хакының 100 проценты күләмендә билгеләнә.

Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшне күз алдында тоткан муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге җирле үзидарә органы җитәкчесенең муниципаль хокукый акты белән билгеләнә.

2.2. Түләүне исәпләү ай саен башкарыла һәм ул җирле үзидарә органының хезмәткә түләү фонды акчалары хисабына хезмәткәрне тотуга аталган акча белән бергә түләнә.

2.3. Муниципаль хезмәткәрләргә түләүне билгеләү турында карар җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан кабул ителә, ә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисенә түләү билгеләү турында – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы тарафыннан.